Татарстан Республикасы “Лениногорск муниципаль районы”  “Лениногорск шәһәре 4 нче гомуми урта белем бирү мәктәбе” гомуми белем бирү муниципаль учреждениесе

# “Гомерем минем моңлы бер җыр иде”

(Лениногорск муниципаль районының татар теле һәм әдәбияты укытучылары  һәм укучылар өчен үткәрелгән әдби кунакханә)

**Төзүче:** беренче квалификацион категорияле
туган тел һәм әдәбият
укытучысы Нуруллина З.С

**“Гомерем минем моңлы бер жыр”**
(әдби кунакханә)

(слайд, М.Җәлил портреты)

*(“Җырларым” җыры яңгырый)*

**1 а.б.** Хәерле көн хөрмәтле кунаклар, укытучылар, укучылар. Герой-шагыйрь Муса Җәлилгә багышланган “ Гомерем минем моңлы бер җыр иде” дигән әдәби кунакханәбезне башлыйбыз.

**2 а.б**. Сәламләү өчен сүзне мәктәбебезнең директор урынбасары Галия Җәмил кызы Хәлимовага бирәбез.

**1 а.б** Сезне “Чишмә” иҗат берләшмәсе җитәкчесе, якташ шагыребез Таһир Ярулла улы Шәмсуаров сәламли.

**1 алып баручы:** 1906нчы елның 15нче февралендә Оренбург губерниясе Мостафа авылында  Муса Җәлил дөньяга килә.

**2 а.б.** Гаиләдә ул алтынчы бала бала була. Әтисе- Мостафа Җәлилов, әнисе – Рәхимә Җәлилова. Башка балалар кебек ул да яланаяк яшел чирәм өстендә йөгергән, казлар көткән, су коенган, әнисенең моңлы җырларын тыңлаган.

(слайд Муса гаиләсе белән)

*(“Ай былбылым” җыры)*

**1а.б.** Шигырьләр язу дәрте Мусада иртә уяна. Туганнан туган апасы Мәрьям Сәйфетдинова искә төшергәнчә, 1915 елларда Муса Г.Тукай кебек бөек шагыйрь буласы килүен әйтә.

(слайд Г.Тукай портреты)

**2 а.б.** Бик күп сикәлтәле юллар үтеп,  Муса белем ала һәм халыкны мәдәнияткә алып чыга. Ул шигырьләр, поэмалар, либретталар иҗат итә. Бер-бер артлы аның китап басмалары чыга, бигрәк тә, балалар өчен.

*( “Родник”, “Карак песи”, “Сәгать”)*

**1 а.б.** Муса Җәлилнең күп кенә шигырьләренә татар халкының күренекле композиторлары көйләр дә язган.

*( “Сәгать” җыры)*

**2 а.б.** Муса Җәлил гади хезмәт кешесенең дә эшен күрә белгән. Аның тырыш

хезмәте турында матур шигырьләр язган.

*("Бер үгет")*

**1 а.б.** Ләкин шагыйрьнең иҗади эшчәнлеге чынга ашмый кала. Бөек Ватан сугышы башлана....

*(Левитан тавышы яңгырый, "Священная война" җыры яңгырый.)*

(слайд "Родина мать" – плакат)

**Диктор тавышы:** Сау булыгыз, дуслар,- диде Муса

Әкрен генә поезд кузгалды

Калды Казан, киттең син сугышка

Ерак иде солдат юллары.

(слайд Муса хәрби киемнән)

**2 а.б.** Сугышның беренче көннәреннән үк Муса фашистларга каршы корал һәм каләм белән көрәшен башлый. Аның сугыш тематикасына багышланган " Дошманга каршы", "Артиллерист анты" җыентыкларында җырлар, патриотик шигырьләр туплана. Шагыйрьнең һәрбер шигырендә Туган илгә, Ватанга мәхәббәт, якыннарга карата җылы хисләр чагыла.

**1 а.б.** 1942 елның июлендә авыр яраланган Муса фашистларга әсирлеккә эләгә. Бу хәл Волхов фронтында була.

(слайд Волхов фронтындагы сугыш кадрлары)

**2 а.б.** Фашист төрмәсе .... Ачлык,ләкин монда да М.Җәлил коралын кулыннан төшерми . Ул фашистларга каршы үзенең сыналган коралы-каләме белән көрәшүен дәвам итә.

**1 а.б.** "Без үлемнән көчлерәк булырга тиеш," – дип Муса үзенең көрштәшләренә берничә тапкыр кабатлый. Бердәмлек, дуслык җәлилчеләргә көч һәм дәрт өсти.

*("Катыйльгә")*

(слайд Плетцензее һәм Моабит төрмәләре)

**1 а.б.** Әсирләрне аерым камераларга ябалар, кулларын, аякларын бәйлиләр. Фашистлар шагырьне кыйныйлар, кулын сындыралар... Сынган, шешкән бармаклары белән Муса шигырьләр язуын дәвам итә.

**2 а.б.** Җиңел булмый шагыйрьгә, ул гаиләсен сагына, кечкенә кызчыгы Чулпанны һәм хатыны Әминәне.

*("Кызыма" шигыре яңгырый)*

(слайд Муса кызы Чулпан белән)

**Диктор тавышы:** Ромашкалар, ромашкалар

Күңелләрдә күпме алар?

Бухенвальдта, Моабитта

Шпандауда- ромашкалар.

(слайд ромашкалар аланы)

*("Кызыл ромашка" шигыре яңгырый )*

**2 а.б.** 1944нче елның 25 августы , иртәнге тынычлыкны солдат аяк тавышлары боза. Акрын гына ишек ачыла.

**1 а.б.** Камерага фашистлар керә. Алар татарларның исемлеген укып, тиз генә чыгарга кушалар.

**2 а.б.** Әсирләр аңлыйлар, бу аларның соңгы сулышы...

**1 а.б.** Ләкин татарлар кулларын кысып, башларын күтәреп, бер-берсенә елмаялар.

**2 а.б.** 1944нче елның 25нче августы 12 сәгать 06 минут, фашист гильотинасы эшли башлый.

(слайд гильотина, кыңгырау тавышы һәм татарларның портреты)

**2 а.б.** Татар халкының бөек улларын юк итәр өчен, фашистларга бары 30 минут вакыт җитә.

**1 а.б.** Туган илнең батыр улларын искә алып, бер минут тынлык игълан ителә.

(*Бер минут тынлык, метроном)*

**2 а.б.** Шагыйрь үлмәде! Аның Туган илгә ике китапчыгы кайта, бу шагыйрьнең төрле илләргә таныш булган “Моабит дәфтәрләре”.

(слайд “Моабит дәфтәрләре”)

*(“Җырларым” шигыре яңгырый )*

**1 а.б.** Әйе, шагыйрь мәңге үлемсез. Муса Җәлилнең бөтен планетага билгеле. Патриотик шагыйрь исемен мәктәпләр, колхозлар, китапханәләр йөртә. Аның исемендә театр, теплоход һәм пароходлар бар. Бүгенге көндә дә аңа, аның батырлыгына багышлап шигырьләр, җырлар иҗат ителә.

*(Т.Шәмсуаров)*

**2 а.б.** Хәзер сүзебезне 11 нче гимназиядән килгән кунакларга бирәбез.

*(гимназия укучылары чыгышы)*

**2 а.б.** Мәктәбебезнең шигрият белән кызыксынучы укучысы С.И... та Муса Җәлилгә багышлап шигырь язган.

(укучы үзе иҗат иткән шигырен сөйли)

**2 а.б.** Без, җәлилчеләр, безнең өчен кан койган солдатлар җиңүе белән бүгенге көндә бәхетле яшибез. Дуслар! Шундый аяз күкле тыныч, матур тормышның кадерен белик.

**1 а.б.** Сезгә җәлилчеләр кебек көчле рух телибез.Сәламәт булыгыз, Туган илебез, туган телебезнең кадерен белегез! Игътибарыгыз өчен зур рәхмәт, сау булыгыз!






1906-1944


Гомерем минем
моңлы бер җыр
1906-1944